ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.05.2022 г. Заинск № 251

**«Бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 10 сентябрендәге 555 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Бинаны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турында нигезләмәне раслау хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган «Бинаны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиеш, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турында нигезләмәнең 61 пунктына үзгәреш кертү хакында» 2022 елның 17 февралендәге 187 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 10 сентябрендәге 555 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1 2.8.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 8 пунктчаны өстәргә - «су басу, су күтәрелү зонасы чикләрендәге җир кишәрлегендә урнашкан бакча йортын урнаштыру (бакча йортын торак йорт дип тану турында гаризаны караганда) ».

2. Башкарма комитетның оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Р.М. Хаҗиповка йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Э.Н. Кулагина
8(85558) 7-08-18